Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы

Карар №3 01.11. 2020 ел

«Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегенең Яңа Үзи авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Аксубай муниципаль районы «Беловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 ст. нигезендә Карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Аксубай районы Яңа Үзи авылы Мәктәп урамы 7 нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында 2020 елның 10 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегенең Яңа Үзи авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Аксубай районы Яңа Үзи авылы Мәктәп урамы 7 нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында 2020 елның 10 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегенең Яңа Үзи авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегенең Яңа Үзи авылында яшәүчеләр исемлеген 2 өлешкә бүләргә:
   1) Чокыр урамы, Чишмә урамы. Адоратский ур., Әмирхан ур., Тынычлык ур.
   2) Тукай ур., Яшьләр ур., Сәлимҗанов ур., Үзәк ур., Бакча ур., Көнбатыш ур.
4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш,һәр балигъ булган һәр кешедән, 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?

**Беловка авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге**

- Яңа Үзи торак пункты чикләрендә юл полотносы урнаштыру, шул исәптән: (грунт күтәрү, грейдерлау, вак таш салу, тигезләү ,килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- авыл юлларына вак таш җәю өчен вак таш сатып алу
- Беловка авыл җирлегенең Яңа Үзи торак пункты чикләрендә юлларны кышкы карап тоту (юлларны кардан чистарту,запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу).

**Күмү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру**

- Яңа Үзи торак пунктындагы зират коймаларын алыштыру (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

« РИЗА»   « КАРШЫ»

5. Әлеге карарны Беловка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга : http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:/ / pravo. tatarstan. ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге
башлыгы башлыгы

И. Р. Мәхмүтов